**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтү буенча эпизоотиягә каршы һәм профилактика чаралары үтәлү белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганакларында:

төньяк киңлекнең 55,404216 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 52,287455 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районы Баграж аучылык хуҗалыгының «Төбәк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территория чикләрендә;

төньяк киңлекнең 55,289283 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,872807 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районының «Карамалы аучылык хуҗалыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территория чикләрендә;

төньяк киңлекнең 55,224519 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,766720 градусы географик координатлары буенча урнашкан Зәй районының «Карамалы аучылык хуҗалыгы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган территория чикләрендә;

төньяк киңлекнең 55,2101 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,6889 градусы географик координатлары буенча урнашкан Әлмәт районының «Ямаш» аучылык хуҗалыгы территориясе чикләрендә;

төньяк киңлекнең 55,0736 градусы һәм көнчыгыш озынлыкның 51,8441 градусы географик координатларыннан 500 метр радиуста урнашкан Зәй районындагы «Елхово урманы» аучылык хуҗалыгы территориясе чикләрендә;

б) Зәй районының Гулкин авылы, Иске Ялан авылы административ чикләрен кертеп, әлеге пунктның «а» пунктчасы алтынчы абзацында күрсәтелгән эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән ким дигәндә 5 км радиуста урнашкан территория чикләрендә;

в) Зәй районының Кабан-Бастрык авылы, Дүртмунча авылы, Бишсубаш авылы, Түбән Биш авылы, Перцовка авылы, Кармалка поселогы, Югары Шепкә авылы, Яңа Пәлчикәү авылы, Нератовка авылы, Түбән Кама районының Югары Уратма авылы административ чикләре кысаларында;

г) Аксубай, Алексеевск, Актаныш, Бөгелмә, Лениногорск, Нурлат, Ютазы районнары административ чикләре кысаларында.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә 180 календарь көн дәвамында түбәндәге чикләүләр саклана:

дуңгызларны, 70ºС югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган сәнәгать эшкәртүе узмаган дуңгызчылык продукциясен һәм аларны эшкәртүдән алынган продукцияне әлеге Указның 1 пункты «г» пунктчасында күрсәтелгән территорияләрдән транспортка төяп чыгаруны тыю;

әлеге Указның 1 пункты «б», «в» һәм «г» пунктчаларында күрсәтелгән территорияләрдә дуңгызларны сатуны тыю.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән тыюлар III һәм IV компартментларга караучы һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә расланган Африка дуңгыз чумасы белән чирләүне бетерү һәм чирнең таралуын кисәтүгә юнәлтелгән профилактика, диагностика, чикләү чараларын һәм башка чараларны тормышка ашыру, карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча ветеринария кагыйдәләренең 37 һәм 38 пунктлары нигезендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, иминлексез һәм чир таралу куркынычы булган территорияләрдән чыгарылган хуҗалыкларга кагылмый.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге ПУ-912 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 26 гыйнварындагы ПУ-56 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 20 февралендәге ПУ-171 номерлы Указы.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 15 май
№ ПУ-381